КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 18 март г.Казань № 187

Төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать тыюлыклары турындагы нигезләмәләрне раслау хакында

«Аеруча саклана торган табигать территорияләре турында» 1995 ел, 14 март, ФЗ-33 нче Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

«Ивановский нарат урманы» төбәк әһәмиятендәге комплекслы юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәне;

«Ленино-Кокушкино» төбәк әһәмиятендәге комплекслы юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәне;

«Язгы адонисны саклау буенча Казан ботаника тыюлыгы» төбәк әһәмиятендәге биологик (ботаник) юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәне;

«Язгы адонисны саклау буенча Урганча ботаника тыюлыгы» төбәк әһәмиятендәге биологик (ботаник) юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәне;

«Владимировка сөзәклеге (Актүбә биләмәсе)» төбәк әһәмиятендәге биологик (ботаник) юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәне;

«Адонис урманы» төбәк әһәмиятендәге биологик (ботаник) юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәне;

«Яңа Александровка сөзәклеге» төбәк әһәмиятендәге биологик (ботаник) юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәне;

«Коржинский сөзәклеге» төбәк әһәмиятендәге биологик (ботаник) юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәне;

«Наратасты урманы» төбәк әһәмиятендәге биологик (ботаник) юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәне;

«Сөлек урманы» төбәк әһәмиятендәге биологик (ботаник) юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәне;

«Иске тегермән» төбәк әһәмиятендәге ландшафт юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәне.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин